Балалар журналы

ISSN 0868-4545

Салават күпере



«Салават күпере аша

Кызык бу дөнья дигәнең...
Кечкенә чакта тизрәк зур үсәсе килә иде. Хәзер менә балачак сагындыра...



Бар иде япь-яшь чаклар:
Кесә тулы – борчаклар...



Язучы абый – Зиннур ХӨСНИЯР.

Моннан күп еллар элек
(Бик күп тә түгел алай!)
Яшәгән Бикнаратта
Зиннур исемле малай!
Көтү көткән, печән чапкан,
Кар көрәгән, каз куган...
Бигрәк тә хирыс булган ул
Укуга һәм язуга.

Зиннур абый ХӨСНИЯР 1961 елның 18 июлендә Биектау районының Бикнарат авылында дөньяга килә. Әтисе Зыятдин ага – балта остасы, тимерче, әнисе Һәдия апа – хәзер үз төбәкләрендә хөрмәтле абыстай.

© "Салават күпере", 2005 ел

...Мин «котырып» әдәби китаплар укыйм. Авыл клубында берничә шкафтан торган китапханә бар иде. Мин андагы китапларның һәркайсын икешәр-өчәр кат укып чыктым. Кыскасы, кулга нинди китап эләгә, шуны укыйм. Күбрәк пьесалар туры килә иде. Унбиш яшьтә шигырьләр язасы килә башлады. Калын дәфтәр башладым...

Зиннур ХӨСНИЯР.

кайтам сабый чагыма...»

ТӘҮГЕ ШИГЫРЬ

Сөйгәнемә

Үз-үземә һәйкәл куярмын күк!
Тфү-тфү, сүзем нәзер булмасын!
Ә син, кызый, сагалый күр:
Ул һәйкәлгә
Күгәрченнәр кунмасын!



Комсомол, спортсмен һәм... гашыйк егет.



Янәшәмдә – Әни, Әти,
Янымда – якыннарым...
Сез булганда һич сүрелмәс
Йөрәгем ялкыннары!

Безнең гаилә – зур гаилә.



Балачакка кайтып барыш
Елларны кичә-кичә...
Күңелдәге хатирәләр
Ап-ак кәгазьгә күчә.



Балачактан истәлек-хатирә

Салават күпере аша узганым бар

Безнең Дөбъяз ягында инешләр күп. Ашыт елгасы да авыл кырыеннан гына ага. Шуңа күрә күперләр дә күп. Агач күперләр, бетон баганаларга утыртылган күперләр.

Салават күпере дә бар безнең якта. Җәй көне җылы яңгырлардан соң күктә пәйда була ул.

Андый Салават күпере сезнең авылда, кыскасы, сезнең якта да бардыр ул, әйеме?

Салават күпере минем туган авыл белән күрше авылларны тоташтырып тора.

Минем шул Салават күпере аша узганым бар. Балачакта инде, әлбәттә. Ничек булдымы? Ышанмыйсызмы? Алайса сөйләп бирмичә булмый инде.

Җәй көне булды бу хәл.

Июль аеның унсигезенче көне. Минем тагын бер яшькә үсеп киткән көнем. Туган көнем була инде. Әнием шул хөрмәткә бик тәмле өчпочмаклар, пәрәмәчләр пешерде. Әниемнең әнисе – ул минем дәү әнием була – күрше Көек авылында яши. Ялгыз башы гына.

Әни миңа кайнар килеш дәү әнигә пәрәмәчләр илтергә кушты. Авыллар арасы дүрт чакрым. Киттем шулай. Мин инде зур егет. Быел көзгә мәктәпкә дә барам әле.

Авылдан чыгып киткәндә күк йөзе ап-аяз иде. Берәр чакрымлап ара узгач... яңгыр ява башламасынмы! Мари урманнары ягыннан бүрек чаклы гына бер болыт килеп чыкты да... Хәер, урманга рәхмәт. Ул болытны шундук үзенә кире тартып та алды. Дәү әнигә пәрәмәч илтәсемне белгән, күрәсең.

1978 елда туган авылыннан өч чакрым ераклыктагы Олы Битаман авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Зиннур Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетына укырга керә.

Ялт итеп күктә Салават күпере пәйда булды. Бер очы безнең авыл башында. Икенче башы дәү әнинең бәрәңге бакчасындагы тупыл агачы төбендә үк.

Матур. Барам шулай сокланып. Инеш аша чыгасым барлыгы да онытылды. Яр буена килеп җиткәч кенә искә төште. Ташлы елга буендагы инешем лым тулып агып ята. Басмасы киткән. Ничек аркылып чыгарга соң моны? Йөзә беләм белүен. Ә пәрәмәчләр?! Алар суга чылана бит.

Тик аптырап басып торам шулай. Пәрәмәчләрем дә суына бугай инде. Җылыйсым да килә башлады. Менә шул чакта, ышанасызмы-юкмы! – инеш буенда Салават күпере калыкты. Мин туп-туры шунда таба киттем. Күпергә кердем. Һәм, тиз-тиз атлап, Салават күпере буйлап бара башладым. Күз ачып йомганчы дәү әнинең тупылы янына килеп тә җиткәнмен.

Пәрәмәчләр кайнар иде әле.

Һәрвакыт булсын!

Кайтканда да Салават күпере аша кайтмакчы идем. Ләкин Алла бабай аны болытлар өстенә күтәреп куйган иде инде. Инешнең дә суы кимегән.

Чалбар балагын сызгансаң, ерып та чыгып була.

Юл буе хыялланып кайттым. Салават күперенә кат-кат рәхмәтләр укыдым. Ул мине инеш аша алып чыкты бит!

Их, мин әйтәм, Салават күпере һәрвакыт булсын иде ул!.. Көз көне дә, кышын, яз көннәре дә булсын иде дип телădем мин. Ул чакта барлык балалар да ничек сөенерләр иде.

Бу минем сабый чак теләгем иде. Бу теләгем бик самими иде. Күрәсең, мин теләк теләгән мизгелләр күк капусының ачык вакытына туры килгән. Нәкъ ике дистә елдан соң ошбу изге теләгем кабул булды лабаса!

Хәзер «Салават күпере» җәй көне генә түгел, һәрвакыт бар ич! Менә, әнә, синең алдыңда бит ул «Салават күпере».

Рәхмәт сиңа, Салават күпере! Теге чакта мине инеш аша чыгардың. Бүген исә кызым белән малаемны ай саен үзеңнең матур әкият-хикәятләрең белән сөендереп торасың!..

Студент елларында институт каршындагы «Илһам» әдәби-иҗат түгәрәгенең актив әгъзаларыннан берсе була, соңга таба аны үзе үк җитәкли. Дүртенче курста укыганда «Ялкын» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире булып эшли башлый.



Узган һәр көн Хәтер булып кала
Күңелләрдә, йөрәкләрдә...
Гомеремнең кайбер мизгелләре
Ошбу фотосурәтләрдә.



Кадерле Әтием, Әнием һәм сеңелем белән.




Ике апам белән янәшә.

Кайчакларда искә төшә
Бик таныш җыру-көйләр:
«Әллә каян күренеп тора,
Солдатта булган, диләр...»



Армиядә. Ял тәтегән вакыт.





Каеш будым билемә...
(Армиядән кайткач,
«Каешлану» дигән кыйсса
язачакмын...)

1985-1987 елларда Зиннур Хөснияр гаскәри хезмәттә, Брест шәһәрендә офицерлар әзерли торган мәктәпне тәмамлый.




Туй уздырып йөргән мәлләр
Хәтердән чыкмый һич тә...
Әй ул көннәр — гүзәл көннәр
Истә, һаман да истә!



Газизләрем белән бергә мин...



Табыштык та кавыштык.



Гомергә бергә булыйк!

Армиядән кайткач, Татарстан радиосында әдәби-драматик тапшырулар редакциясе мөхәррире, аннары берникадәр вакыт Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли ул.



Олы чагымда яшим,
Бала чагым – истә гел.
Бу язмаларым – Сезгә:
Балачактан истәлек!



Хатирә-истәлек

Чикерткә җиккән идек...

Кызык кына инде бу дөнья!

Сабый чакта минем әтием кебек зур кеше буласым килә иде. Тизрәк үсәсем килә иде!..

Хәзер, инде яшем кырыктан узгач, сабыйчакка кайтасым килә. Гаҗәп инде, әйеме: әүвәл тизрәк үсәсе килә, үсеп җиткәч, балачакны сагынасың!

Киттем әле мин балачакка.

Туган авылымны икегә аерып, инеш ага. Без балачакта коенып үскән сай сулы инеш. Каз бәбкәләре белән бергәләшеп коена идек. Балачак инеше белән киңәш-табыш итәргә булдым.

– Әй, инешкәй, сиңа гозерем бар! Тыңла әле!

– Әйт сүзеңне, авылдаш. Ни булды?

– Син минем балачакны хәтерлисең бит, инешкәй? Минем кабат шул балачагыма кайтып киләсем килә...

– Әлбәттә, хәтерлим. Миндә син йөзәргә өйрәндең. Бака малайлары белән бергәләп чупырдый идегез инде.

– Алып кайтып килче мине балачагыма, инешкәй, ә!

– Балачагыңа?! Син балачакта минем суымда башыңнан күмелә идең. Хәзер мин синең тезеңә дә җитмим бит. Үзең дә хәтерлисең, сез сабый чакта ук дәү абыйлар минем ярларны тракторлар белән актарып, казып бетерделәр. Суым кибеп, каз бәбкәләренең дә түшеннән генә калды. Шулай булгач...

– Аңладым, инешкәй. Әйе, без, кешеләр, сине саклый алмадык шул...

Мин үзебез балачакта башларыннан төшмәгән өянкеләр янына киттем.

– Әй, өянке! Минем балачакны хәтерлисең бит син, әйеме?

– Хәтерләмәгән кая! Малай чакта минем очымнан төшми идең.

– Балачагыма алып кайтып кил әле мине, өянке агай, ә?

– Балачагыңа? Һе... кызык фикер бу! Тик бер зур мәсьәлә бар шул. Элек мин янәшәмдә туганнарым булганда бик көчле, гайрәтле идем. Күрәсең, минем туганнарымны кешеләр утынга турап бетерде. Мине кисмәкчеләр иде, үзе корый дип кенә калдырдылар. Шулай булгач...

Өметем тәмам өзелде. Күңелем сүрелде, кәеф төште. Ләкин шулчак инеш буенда бер таныш тавыш ишетелмәсенме? Һай! Чикерткә җыры ләбаса бу! Минем балачак чикерткәсе! Мин тавыш килгән якка йөгердем.

– Әй, яшел чикерткә, дустым, исәнме!

– Исәнме, авылдаш!

– Яшел чикерткә, хәтерлисеңме, мине бит балачагымнан сез алып киттегез. Мин сезнең өчегезне бер салам тәртәгә җиктем дә... балачактан китеп барган идем... Кире алып кайтып килче, ә?!

– Булмый, якташ. Күрәсезме, мин хәзер үзем генә, ялгыз башым калдым. Тракторлар белән болын-кырларны сукалап, актарып бетерделәр дә... чикерткәләргә яшәргә Ватан калмады. Ә мин бер үзем генә тәртә арасына җигелә алмам инде, бигайбә, яме!..

Әйе, ни кызганыч, балачактан алып чыгып киткән чикерткәләр дә мине кире алып кайта алмыйлар.

Балалар! Балачакның кадерен белегез, тәмен белеп яшәгез. Соңыннан соң булыр, күрәсез, анда башка кире кайтып булмый.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Балкый



Баш мөхәррир Зиннур абый
Күп еллар инде менә
«Салават күпере» белән
Сабыйлар сөендерә!



«Салават күпере» журналын оештыручылар һәм тәүге саннарын чыгаручылар: Ләбиб Лерон (бүлек мөхәррире), Фирая Бәдретдинова (җаваплы сәркатип), Зиннур Хөснияр (баш мөхәррир), Айдар Үтәгән (бизәлеш мөхәррире). 1990 ел.

1989 елның ахырларында Зиннур Хөснияр Татарстан Язучылар берлеге белән берлектә һәм «ПОИНТ» совет-фин уртак предприятиесе (җитәкчесе – эшмәкәр-журналист Солтан Сәлимҗанов) ярдәмендә татар балалары өчен төсле-бизәүле «Салават күпере» исемле журналга нигез сала һәм журналның баш мөхәррире итеп тәгаенләнә.

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ» — яктысы көнелләрдә



ДИПЛОМ

«Ел журналы»

номинациясендә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ

«БӘЛЛҮР КАЛӘМ - 99»

ЖУРНАЛИСТЛАР КОНКУРСЫ

ЛАУРЕАТЫ

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ»

ЛАУРЕАТ

ЖУРНАЛИСТСКОГО КОНКУРСА

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

«ХРУСТАЛЬНОЕ

ПЕРО - 99»

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ»

в номинации


«Журнал года»

ЗИЛЯ ВАЛЕЕВА

ИЛЬШАТ АМИНОВ

РИММА РАТНИКОВА

«Салават күпере» – «Бәллүр каләм»гә лаек булды!



Татарстан Республикасы Язучылар берлеге

Татарстан Язучылар берлегенең

балалар әдәбияты буенча

АБДУЛЛА АЛИШ

исемендәге премиясе

Балалар иҗатын үстерүдәге,

татар балалар әдәбиятын пропагандалаудагы һәм

Абдулла Алиш исемен мәңгеләштерү юнәлешендә

алып барган фидакарь хезмәтләре өчен

"САЛАВАТ КҮПЕРЕ"

журналы редакциясенә

бирелә

Татарстан язучылар берлеге рәисе И. М. Ибраһимов

Казан шәһәре

29 сентябрь 2005 ел

«Салават күпере» – Абдулла Алиш исемендәге бүләк иясе!







2001 елда нигезләнгән «Сәхнә» исемле театр һәм эстрада журналы – Зиннур Хөсниярның шәхси инициативасы һәм матди кайгыртуы белән, аның үз нәширлегендә һәм мөхәррирлегендә дөньяга килгән басма.





Зиннур ХӨСНИЯР

Куян күчтәнәче
яки тешсез малай

Биш яшьлек Булат, әтисе белән әнисе эштән кайтып керүгә:

– Миңа бүген нәрсә алып кайттыгыз? – дип тинтерәтә.

Гадәттә, аңа чит ил сагызы яки кәнфит кирәк инде. Әтисе аны «куян күчтәнәче» дип атый. Ышанасызмы, юкмы – көн саен кәнфит суыра торгач, берзаман Булатның тешләре коела башлады!

Аны бар кеше дә: «Тешсез малай! Тешсез бабай!» – дип үчекли. Булат моңа бик тә гарьләнә, хурлана. Ә үзе һаман кәнфит сорый.

Шуннан соң Булатка көн саен «куян күчтәнәче» итеп кишер алып кайта башладылар. «Куян күчтәнәче» булгач, малай кишерне бик тәмләп ашый инде.

Берзаман, күпмедер вакыт узгач, Булатка яңа тешләр чыга башламасынмы! Ап-ак, энҗе кебек матур тешләр инде менә! Ә куяннар бик хәйләкәр икән бит ләбаса! Тешләре матур булсын дип ашый икән бит алар кишерне!..

Булатны хәзер бер кеше дә: «Тешсез малай! Тешсез бабай!» дип үчекләми инде.





Улы Булат белән

Рәссам Илдар НӘФИЕВ



Апалар берни белми

Булат белән Зилә һәр җәйдә авылга кайта. Авылда бик тә күңелле шул. Әнә, алма кебек кызарып пешкән кояш урман артына йокларга җыена. Тузан туздыра-туздыра көтү дә кайтып җитте. Урам бетереп, әниләреннән аерылып калган бәрәннәр җылаша. Ул әйткәнне аңласалар, Булат аларга: «Җылаудан файда юк! Тамагыгызны гына бетерәсез!» – дияр иде.

Шул арада тау астындагы инештән, бак-бак килеп, үрдәкләр кайтып килә. «Шулхәтле бакылдамасагыз! Туйдым тавышыгыздан!» – дип каршылый аларны күрше апасы. Үрдәкләрнең ни сөйләгәнен аңламый, телләрен белмидер ул. Инештә кайсы күпме бака тотканны саный ич алар!

Кулларына ипи сыныгы тоткан апалар адашып калган малларын эзли. Әнә, арт аякларына баскан мут кәҗәләр капка төбендәге агачка үрелә. Көтү кайткач, Булатның төп эше агачны кәҗәләрдән саклау. Өлкәннәр кушканча, кәҗәләрне таяк белән кыйнамый ул. Бераз читтәрәк яткан бүрәнәләр өеменә таба куа. Кәҗәләр, бик теләп, агач каезларга керешә – Булатның дәү әтисенә булышалар.

Менә абына-сөртенә сыер да кайтып керде. Булатка тизрәк тәмле сөт эчертәсе килгәндер инде. Әллә апасы, сөзәрләр дип, курка аңардан. Кичә яңа сауган сөтне эчмәгән иде ул. Шуңа күрә аңа сыерның бик тә ачуы килгән.

Дәү әнинең ата казлары чыннан да усал менә! «Сиңа үпкәләгән ул. Бәбкәләрен алырга тилгән килгән булган. Ә син, уен белән мавыгып, тилгәнне куып җибәрмәгәнсең! Үпкәләгән сиңа ата каз!» – ди дәү әнисе. Булатның ата каз белән һич тә дошманлашасы килми. Тилгән тагын килсә, аны куркытырга, тылсымлы сүзләр дә өйрәнеп куйды инде.

Тилгән, тилгән,
Бер аягың тимердән,
Бер аягың камырдан,
Бәбкә урларга килгән!
Көш! Көш!..

Ә әтәчләр, бер-берсе белән күрешкәч, сугышырга гына тора. Өлкәннәр аларны тырыша-тырыша аера. Белмиләр, аңламыйлар! Үз тавыкларының дәрәҗәсе өчен көрәшә алар. Кемнең тавыклары күпме йомырка салган янәсе. Күрше әтәче, минем тавыкларым күбрәк, дип мактана. Икенчесе үз ягына каера. Имеш, аның тавыклары күкәйне



Кызы Зилә белән

күбрәк сала икән.

Җә, көтү дә кайтып бетте инде. Бүген мунча якканнар иде. Әтисе белән мунча керәсе бар Булатның. Әтисе, ләүкәгә салып, чабындыра да әле аны. Ул бер тамчы да җыламый. Бүтәннәр моңа ышанмый, әлбәттә. Авыл мунчасында чабыну кешенең эчендәге шайтаннарны куып чыгаруын белми торгандыр алар. Ә Булат белә – әтисе әйтте.

Монысы әлегә соңгы мунча инде. Иртәгә Казанга кайтып китәсе. Әтиәнисенең еллары беткән, эшкә чыгасы, ди. Булат та, Зилә апасы да сагынырлар инде авылны!

Шәһәрдән кунакка кайткан күрше апасы: «Бик сагынсаң, бу тавык-чебешләрне, кәҗәләрне Казаныгызга алып кит!» – ди. Әмма ничек итеп? Бүген аларны алып китсәң, калганнары үпкәләп кала бит! Менә капка төбендә үскән бу агачны ничек алып китәсең, ди? Бәлки Авылның үзен алып китәргәдер? Аннан соң Казанда җәен дә, кышын да гел Авыл гына булыр иде.

Тик, Авылсыз калгач, дәү әтисе белән дәү әнисе нишләр соң? Бүтән кешеләр нишләр?..

Юк, кунак апа дөрес әйтми. Булатны котыртмасын да, аптыратмасын да! Аптыраган үрдәк арты белән суга чума, дип әйтергә ярата дәү әнисе.

Ә Булат йөзә белми әле...



Илбашы белән янәшә

«Хезмәте барның –
хөрмәте бар» –
Хак әйтә икән халык:
Илбашы бүләк тапшыра –
Торамын хәйран калып!






Зиннур Хөсниярның тәүге китабы – «Таң ата да кич була» исемле хикәяләр җыентыгы 1989 елда басылып чыга. Шуннан соң аның «Тәгәри китте язмышлар» (1991) исемле проза җыентыгы, «Терсәк сугышы» (2001) һәм «Эттән туган» (2003) роман-китаплары бер-бер артлы укучылар кулына барып ирешә. Язучы «Ак болыт күләгәсе», «Хуҗа һәм аның хатыны», «Кышлаган үгез» хикәяләре өчен 2001 елда Татарстан Язучылар берлегенең Фатих Хөсни исемендәге премиясе белән бүләкләнде.


З.Хөснияр – татар балалар әдәбияты өлкәсендә дә актив авторларның берсе. 1996-2004 еллар арасында аның кече яшьтәге балалар өчен биш китабы басылып чыкты. Ул 2001 елдан «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем йөртә.

Язучы Зиннур Хөснияр иҗаты турында татар әдипләренең фикерләре



Зиннур авыл егете, ул авылны белә, ул авыл кешеләре турында язачак. Хәтта шәһәр җирлегендә булган вакыйгаларда да хикәя каһарманнары авыл турында уйлый, авылны сагына... Авыл – безнең язмышыбыз, авыл – безнең якты өметебез! Авыл бетсә, тел дә, матур гадәтләр дә, халык та бетәчәк.

Рабит БАТУЛЛА,
1989



Зиннур Хөснияр хикәяләре салмак сурәтләүләр, романча тасвирлаулар, кайтып-кайтып укырлык, уйландырырлык тирән мәгънәле гыйбарәләр белән ачыла. Татарның үзе кебек, сабыр да бу хикәяләр, аларда бомба да шартламый, мылтык та атмый, үтерешләр дә юк...

Фәнзаман БАТТАЛ,
1989



Мине иң сөендергәне – язучының кешеләргә хөкем чыгармавы. Хөкемне ул укучыларга калдыра.

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ,
1989



З.Хөсниярның «Терсәк сугышы» романы сурәтләнгән тормыш материалының заманчалыгы, чор проблемаларына бәйле фәлсәфи һәм әдәби-эстетик карашлары, кызыклы образлары белән хәтердә кала. Язучы без яши торган кешелексез җәмгыятьне һәм шундый шартлар тудырган кешеләрне укучы хөкеменә чыгара. Әсәрнең кыйммәте дә әнә шулар белән аңлатыладыр.

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ,
2002



Зиннур Хөсниярның «Терсәк сугышы» романы тормышның кырыс кануннары белән очраштыра. Кеше һәм аның эчке дөньясы, табигать һәм кеше мөнәсәбәтләрендә безнең буын язмышы, рухи халәте ачык буяулар белән тасвирлана.

Факил САФИН,
2002





Кадерле кадрлар








Зиннур ХӨСНИЯР сүзләре
Алмаз ИМАЕВ көе

Шүрәле

Ачуланган, турсайган,
Шүрәлене күр әле!
Онытырга вакыт инде
Былтыргы үпкәләрне.
Әй, Шүрәле, Шүрәле,
Безнең янга кил әле.
Син яхшы бит, син әйбәт бит,
Теге хәлне сөйләле.
Әкияттән чыктыңмы,
Урманнан киләсеңме?
Әгәр булсаң чын Шүрәле,
Кытыклап кара безне.
Бигрәк озын кулларың,
Күзләрең йөреп тора.
Килеш-килбәтеңне күргәч,
Көләсе килеп тора.
Әй, Шүрәле, Шүрәле,
Безнең янга кил әле.
Син яхшы бит, син әйбәт бит,
Бергәләп көлик әле.



Рәссам Фәрит Муллахмәт

Сәләвәт күпере

10 (199) — 2006

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРУЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Д.НӘҮРУЗОВА рәсеме
Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиесе.
Казан, Декабристлар урамы,2 нче йорт.

Производствога бирелде 9.10.2006 ел.
Басарга кул куелды 9.10.2006 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тираж 10124 данә. Заказ 3-871.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, Н.Акмал, З.Вакказова, Г.Сабирова.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



Зиннур ХӨСНИЯР

Балачакка кайту

Күбәләк куышлый гына
Чыгып кителгән иде, –
Шул балачак иленә
Кайтасы килә кире.

Чикерткәләр җигеп кенә
Чыгып кителгән иде, –
Балаларым белән бергә
Кире кайтышым инде.

Ак болытларга утырып,
Чыгып кителгән иде...
«Салават күпере» белән
Бергә кайтам ич инде.